**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ "ЗЕЛЕНАЯ РОЩА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**ИЛЛЕ ӨЧЕНЧЕ СЕССИЯ**

**2 НЧЕ НОМЕРЛЫ КАРАРЫ**

**Зеленая Роща авылы, 2024 елның 23 сентябре**

**Бөгелмә муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2020 елның 12 ноябрендәге II сессиясенең 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Бөгелмә муниципаль районының «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

карар кылды:

1. Бөгелмә муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2020 елның 12 ноябрендәге 2 номерлы II сессиясе карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 пунктны, 2 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) - Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2025 - 2027 елларга күчеш чорына 1,2 процент;

- 2025 елга һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент.

Әлеге карарның 2 өлешендәге 4 пунктында күрсәтелгән күчеш чорлары узгач, физик затлар мөлкәтенә салым ставкалары Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 һәм 2.1 пунктчалары нигезендә билгеләнә.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**"Зеленая Роща авыл җирлеге"**
**муниципаль берәмлеге Советы**
**башлыгы Д. М. Хикмәтов**